# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Күмәк аңлашманамәләр һәм килешүләр
турында

## I бүлек. Төп төшенчәләр

1 маддә. Законның максатлары һәм тәэсир итү өлкәсе

Әлеге Закон хезмәт мөнәсәбәтләрен аңлашманамә белән җайга салуга ярдәм итү, хезмәткәрләрнең һәм эш бирүчеләрнең җәмгыяви-икътисадый мәнфәгатьләрен яраклаштыру максатларында күмәк аңлашманамәләрнең һәм килешүләрнең хокукый нигезләрен билгели.

Закон тәэсире, милек рәвешләренә, нинди ведомствога буйсынуларына һәм хезмәткәрләрнең санына карамастан, барлык предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга кагыла.

2 маддә. Төп билгеләмәләр

Күмәк аңлашманамә - предприятиедә, учреждениедә, оешмада /алга таба - предприятие/ хезмәткәрләр белән эш бирүчеләр арасындагы хезмәт, җәмгыяви-икътисадый һәм һөнәр мөнәсәбәтләрен җайга салучы хокукый акт.

Килешү - аерым һөнәр, аерым тармак, аерым территория хезмәткәрләре өчен хезмәт шартларын, эш белән тәэмин итү һәм җәмгыяви гарантияләрне билгеләү турында йөкләмәләрне үз өстенә алган хокукый акт.

3 маддә. Законнар һәм күмәк аңлашманамә, килешү, хезмәт аңлашманамәсе /контракты/ арасындагы нисбәт

Законнарга туры китереп төзелгән күмәк аңлашманамәләрнең

һәм килешүләрнең шартлары яклар өчен мәҗбүри була.

Хезмәткәрләрнең хәлен законнардагыга караганда кыенлаштыручы күмәк аңлашманамәләрнең һәм килешүләрнең шартлары дөрес булмый.

Хезмәткәрләрнең хәлен законнардагыга, күмәк аңлашманамәләрдәгегә һәм килешүләрдәгегә караганда кыенлаштыручы шартларны хезмәт аңлашманамәләренә /контрактларга/ кертү тыела.

4 маддә. Күмәк аңлашманамәләрне һәм килешүләрне төзү үзенчәлекләре

Күмәк аңлашманамәләрне һәм килешүләрне төзүнең үзенчәлекләре түбәндәгеләр:

законнарны үтәү;

яклар вәкилләренең тулы вәкаләткә ия булулары;

якларның тигезлеге;

күмәк аңлашманамәләрнең һәм килешүләрнең эчтәлеген тәшкил итүче мәсьәләләрне сайлап алу иреге һәм алар хакында фикер алышуларның хәбәрдарлыгы;

йөкләмәләрне ирекле кабул итү;

кабул ителүче йөкләмәләрнең тәэмин ителеше хак булу;

тикшерүнең даимилеге һәм җаваплылыкның мәҗбүрилеге.

5 маддә. Күмәк аңлашманамәләрне һәм килешүләрне төзү, яңадан карау һәм үтәү буенча эшчәнлеккә каршылык күрсәтелмәүнең зарурияте

Күмәк аңлашманамәләрне һәм килешүләрне төзегәндә, яңадан караганда һәм үтәгәндә башкарма хакимият һәм хуҗалык идарәсе органнары, сәяси фиркалар һәм башка төрле иҗтимагый берләшмәләр, эш бирүчеләр тарафыннан хезмәткәрләрнең һәм аларның вәкилләренең законлы хокукларын чикләүче яисә шушы хокукларны гамәлгә ашыруда комачаулаучы теләсә нинди тыкшынулар тыела.

Эш бирүчеләр оештырган яисә законнарда каралган финанслау очракларыннан тыш, эш бирүчеләр финанслый торган оешмалар яисә органнар, башкарма хакимият һәм хуҗалык идарәсе органнары,

сәяси фиркаләр хезмәткәрләр исеменнән сөйләшүләр алып барырга яисә күмәк аңлашманамәләр һәм килешүләр төзергә тиеш түгел.

П бүлек. Күмәк сөйләшүләр

6 маддә. Сөйләшүләр алып баруга хокук

Теләсә кайсы як күмәк сөйләшүләрне оештыручы, күмәк аңлашманамә , килешүне төзүче һәм үзгәртүче инициатор буларак эш итә ала.

Элеккеге күмәк аңлашманамә, килешү вакыты беткәнче, өч ай дәвамында яисә шул документларда билгеләнгән вакыт эчендә теләсә кайсы як яңа күмәк аңлашманамә, килешү төзү буенча сөйләшүләр башлау турында икенче якка язмача хәбәр җибәрә ала.

Каршы яктан сөйләшүләр башлау хакында язма хәбәр алган як җиде көн эчендә сөйләшүләрне башларга тиеш.

Хезмәткәрләр исеменнән сөйләшүләр алып баруга хокук профсоюз оешмаларының/алга таба - профсоюзлар/ тиешле органнарына, ә алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләтләр тапшырылган үз вәкилләренә бирелә.

Предприятиедә республика, тармак һәм территория дәрәҗәсендә берничә профсоюз булган очракта, һәр профсоюз үзе берләштергән профсоюз әгъзалары яисә хезмәткәрләр арасындагы үз вәкилләре исеменнән сөйләшүләр алып бара ала.

Профсоюзлар тарафыннан, алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләтләр тапшырылган вәкилләре тарафыннан карарга тәкъдим ителгән хезмәт һәм җәмгыяви-икътисадый мәсьәләләр турында сөйләшүләрне эш бирүчеләр, дәүләт идарәсе органнары алып барырга тиеш.

7 маддә. Сөйләшүләрне алып бару тәртибе

Күмәк сөйләшүләр алып бару һәм күмәк аңлашманамә, килешү проектын әзерләү өчен яклар тигез хокуклы нигездә кирәкле вәкаләтләр тапшырылган вәкилләреннән комиссия төзиләр.

Комиссиянең составы, сөйләшүләрне уздыру вакыты, урыны һәм көн тәртибе яклар карары белән билгеләнә.

Сөйләшүләрдә катнашучы якларга күмәк аңлашманамәнең ,килешүнең эчтәлеген тәшкил итүче мәсьәләләрне сайлап алу һәм карау иреге тулысынча бирелә.

Башкарма хакимият органнары, эш бирүчеләр һәм аларның берләшмәләре профсоюзларга, алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләтләр тапшырылган үз вәкилләренә үзләрендә булган һәм сөйләшүләр өчен кирәкле мәгълүматларны бирергә тиеш. Әгәр алынган мәгълүмат дәүләт яисә сәүдәгәрлек сере икән, сөйләшүләрдә катнашучылар, башка затлар, сөйләшүләргә бәйле кешеләр әлеге мәгълүматларны игълан итмәскә тиешләр. Әлеге мәгълүматларны игълан иткән затлар законнарда билгеләнгән җаваплылыкка тартылалар.

Әгәр сөйләшүләр барышында яклар үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында уртак фикергә килә алмыйлар икән, ул вакытта каршылыклар беркетмәсе төзелә, аңа яклар тарафыннан килешенгән мәсьәләләр дә, каршылыкларның сәбәпләрен юкка чыгарырлык чаралар турында тулысынча бәян ителгән тәкъдимнәр дә, шулай ук сөйләшүләрне дәвам итү вакыты да теркәлә.

8 маддә. Каршылыкларны хәл итү

Каршылыкларны җайга салу өчен күмәк сөйләшүләр барышында яклар килештерүче гамәлләр кулланалар.

Каршылыклар беркетмәсе төзегәннән соң яклар өч көн дәвамында консультацияләр уздыралар, үзләре арасыннан килешү комиссиясе төзиләр, комиссиядә килешүләргә ирешмәгәндә, яклар килешү буенча сайланган арадашчыга мөрәҗәгать итәләр.

Килешү комиссиясе яисә арадашчы җиде көн эчендә каршылыклар беркетмәсен карарга һәм бәхәснең асылы буенча тәкъдимнәр кертергә тиеш.

Яклар арасында килешү ирешелмәсә кертелгән тәкъдимнәргә карата законнарга каршы килми торган тәртиптә эш ташлауны оештырырга һәм эш ташларга мөмкин.

Күмәк аңлашманамәне, килешүне әзерләү, төзү яисә үзгәртү хакында сөйләшүләр алып барганда, үз таләпләрен яклау рәвешендә, профсоюзлар, алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләтләр тапшырылган үз вәкилләре эштән соң, предприятие эшчәнлеген бозмыйча, җыелышлар, митинглар, пикетлар, демонстрацияләр уздырырга хаклы.

9 маддә. Сөйләшүләр чоры өчен гарантияләр һәм компенсацияләр

Предприятиеләрдә һәм оешмаларда якларның вәкилләре буларак сөйләшүләрдә катнашучы затлар, шулай ук комиссия эшендә катнашу өчен чакырылган белгечләр сөйләшүләр чорына - өч айдан да озак булмаган чорга, уртача хезмәт хаклары саклаңган килеш, төп эшләреннән азат ителәләр, сөйләшүләрдә катнашкан чор хезмәт стажына керә. Сөйләшүләрдә катнашу аркасында килеп чыккан барлык чыгымнар хезмәт, күмәк килешү, аңлашманамә турындагы законнарда каралган тәртиптә компенсацияләнәләр.

Яклар килешүе буенча чакырылганнарның, экспертларның һәм арадашчыларның хезмәте өчен түләү, алар белән сөйләшү нигезендә,

башкарма хакимият һәм хуҗалык идарәсе органнары, эш бирүчеләр /аларның берләшмәләре/ тарафыннан башкарыла.

Күмәк сөйләшүләрдә катнашучы профсоюз оешмаларының һәм хезмәт коллективларының вәкилләре күмәк сөйләшүләр алып барган вакытта дисциплинар җәзага тартыла, башка эшкә күчерелә яисә, аларга вәкаләт биргән орган белән алдан килешмичә, администрация инициативасы нигезендә икенче урынга күчерелә, эшеннән азат ителә алмыйлар.

## Ш бүлек. Күмәк аңлашманамә

**10 маддә.** Күмәк аңлашманамә төзү кирәклеге хакында карар кабул итү хокукы

Эш бирүче белән күмәк аңлашманамә төзү кирәклеге хакында карар кабул итү хокукына, вәкаләтле орган сыйфатында, профсоюз яисә хезмәт коллективының гомуми җыелышы /конференциясе/ турыдан-туры ия була.

**11 маддә.** Күмәк аңлашманамәнең яклары

Күмәк аңлашманамә бер яктан - бер яисә берничә профсоюз сыйфатында, хезмәткәрләр тарафыннан, алар булмаганда - хезмәт иясенең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләтләр тапшырылган үз вәкилләре тарафыннан, икенче яктан - эш бирүчеләр тарафыннан турыдан-туры яисә аларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан төзелә.

Милек рәвешләренә, нинди ведомствога буйсынуларына һәм хезмәткәрләренең санына карамастан, күмәк аңлашманамә предприятиеләрдә, аларның юридик хокукы булган структур берәмлекләрендә төзелә.

**12 маддә.** Күмәк аңлашманамә әзерләүнең һәм төзүнең тәртибе һәм вакыты

Күмәк аңлашманамә әзерләүнең һәм төзүнең әлеге Законның

җиденче маддәсендә каралган тәртибе, вакыты, комиссия составы, сөйләшүләрне уздыру урыны һәм көн тәртибе яклар тарафыннан билгеләнә һәм предприятие буенча - боерык, хезмәт коллективының яисә профсоюзның карары рәвешендә рәсмиләштерелә.

Әгәр хезмәткәрләр ягыннан берьюлы берничә профсоюз катнашырга теләсә, алар сөйләшүләр алып бару, уртак проект әзерләү һәм бердәм кумәк аңлашманамә төзү өчен үзләренең берләштерелгән вәкаләтле органын төзергә тиеш.

Күмәк аңлашманамәнең бердәм проекты предприятие бүлекчәләрендә хезмәткәрләр тарафыннан каралырга һәм, кисәтүләрне, тәкъдимнәрне, өстәмәләрне искә алып, эшләнеп бетәргә тиеш. Эшләп бетерелгән бердәм проект хезмәт коллективының җыелышы /конференциясе/ тарафыннан раслана, һәм аңа хезмәткәрләр ягыннан бердәм вәкаләтле органда катнашучыларның барысы да имза сала.

Бердәм вәкаләтле органда килешүгә ирешелмәгәндә, хезмәт коллективының җыелышы /конференциясе/ күмәк аңлашманамәнең иң яраклы проектын кабул итә һәм әлеге проектны әзерләүче профсоюзга аны эшләп бетерүне һәм шуның нигезендә сөйләшүләр уздыруны һәм, гомуми җыелыш /конференция/ раслаганнан соң, хезмәт коллективы исеменнән эш бирүче белән күмәк аңлашманамә төзүне тапшыра.

Һәр профсоюз сөйләшүләрне мөстәкыйль алып барырга һәм, хезмәткәрләрнең вәкиле буларак, күмәк аңлашманамәне мөстәкыйль төзергә һәм күмәк аңлашманамәгә һөнәрләре буенча хезмәткәрләрне якларлык өстәмә кертергә хаклы. Өстәмә - күмәк аңлашманамәнең аерылгысыз өлеше, һәм ул аның белән бертигез юридик көчкә ия.

Эш бирүче профсоюзларга, алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешенчә сайланган һәм вәкаләтләр тапшырылган үз вәкилләренә үзләре әзерләгән күмәк

аңлашманамә проектларын һәр хезмәткәргә җиткерү мөмкинлеген тәэмин итәргә, үзендә булган эчке элемтә һәм мәгълүмат чараларын, ишәйтүче һәм башка оргтехниканы, эш вакытыннан тыш җыелышлар, консультацияләр үткәрү өчен бина, стендлар урнаштыру өчен урыннар бирергә тиеш.

Күмәк аңлашманамәгә имза салу хакында яклар җиде көн эчендә югарыдагы тиешле хуҗалык һәм профсоюз органнарына, республиканың хезмәт органына һәм эш белән тәэмин итү органына, шулай ук башка кызыксынучы органнарга үз үтенечләре буенча хәбәр итәргә тиеш.

13 маддә. Күмәк аңлашманамәнең эчтәлеге һәм төзелеше

Күмәк аңлашманамәнең эчтәлеге һәм төзелеше яклар тарафыннан билгеләнә.

Күмәк аңлашманамәгә эш бирүче белән хезмәткәрләрнең түбәндәге мәсьәләләр буенча үзара йөкләмәләре кертелә:

хезмәт хакының рәвеше, системасы һәм күләме, акчалата бүләкләр, пособиеләр, компенсацияләр, өстәмә түләүләр;

бәяләр үсешеннән, инфляция дәрәҗәсеннән, күмәк аңлашманамәдә билгеләнгән күрсәткечләрне үтәүдән чыгып, хезмәт хакын көйләү механизмы;

эш белән тәэмин ителеш, яңа һөнәргә өйрәтү, хезмәткәрләрне эштән азат итү шартлары;

эш вакытының һәм ял, отпусклар вакытының дәвамлылыгы;

хезмәткәрләрнең, иң беренче чиратта хатын-кызларның һәм яшьләрнең /яшүсмерләрнең/ хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтен саклау;

ирекле һәм мәҗбүри медицина һәм җәмгыяви страхование;

предприятиене, аңа караучы торакны хосусыйлаштырганда хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен кайгырту;

җитештерүдә эшләүче хезмәткәрләрнең экологик иминлеген, хезмәтләрен һәм сәламәтлекләрен саклау;

күмәк аңлашманамәләрнең үтәлешен тикшерү, якларның җаваплылыгы, җәмгыяви партнерлык, профсоюзларның, ә алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле рәвештә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләрен нормаль эшләү шартлары белән тәэмин итү;

әлеге күмәк аңлашманамәгә кертелгән шартларны үз вакытында һәм тулысынча үтәгәндә эш ташлаулардан баш тарту.

Күмәк аңлашманамәдә башка йөкләмәләр дә булырга мөмкин, шул исәптән законнарда һәм килешүләрдә билгеләнгән нормалар һәм положениеләр белән чагыштырганда күбрәк ташламалы хезмәт йөкләмәләре һәм җәмгыяви-икътисадый йөкләмәләр /өстәмә отпусклар, пенсияләргә өстәмәләр, пенсиягә вакытыннан алдарак китү, укып эшләүче хезмәткәрләр өчен ташламалар, транспорт һәм командировкалар өчен тотылган чыгымнарны компенсацияләү, хезмәткәрләрнең җитештерү урынында һәм аларның балаларының мәктәпләрдә һәм мәктәпкәчә учреждениеләрдә түләүсез яки өлешчә түләүле туклануулары, башка өстәмә ташламалар һәм компенсацияләр/.

Күмәк аңлашманамәгә түбәндәге очракта норматив положениеләр кертелә, әгәр күмәк аңлашманамәдә бу положениеләрне беркетү тиешлеге турында гамәлдәге закон актларында турыдан-туры күрсәтмә булса.

<u>14 маддә.</u> Күмәк аңлашманамәнең көче

Күмәк аңлашманамә 1 елдан 3 елга кадәр вакытка төзелә.

Күмәк аңлашманамә яклар имза салган мизгелдән яисә күмәк аңлашманамәдә билгеләнгән көннән үз көченә керә һәм үзенең тиешле вакытына кадәр гамәлдә кала.

Билгеләнгән вакыт үткәч күмәк аңлашманамә, яклар тарафыннан яңасы төзелгәнче яки гамәлдәгесен үзгәрткәнче, тулыландырганчы, үз көчендә кала.

Предприятие белән идарә итү органының составы, төзелеше, исеме үзгәргән, предприятие җитәкчесе белән хезмәт аңлашманамәсен /контрактны/ өзгән очракта күмәк аңлашманамә үз көчен саклый.

Предприятиене үзгәртеп корганда күмәк аңлашманамә үзгәртеп кору чорына үз көчендә кала, аннан соң берәр якның тәкъдиме белән яңадан каралырга мөмкин.

Предприятиеләр мөлкәтенең милекчесен алыштырганда күмәк аңлашманамәнең көче өч ай дәвамында саклана. Бу чорда яклар яңа күмәк аңлашманамә төзү яисә гамәлдәгесен саклау, аны үзгәртү һәм тулыландыру турында сөйләшүләр башларга хаклы.

Күмәк аңлашманамәне яңадан карау барышында хезмәткәрләр өчен элеккеге күмәк аңлашманамәдә каралган ташламаларны саклау һәм башка шартларны үтәү мөмкинлеге турындагы мәсьәлә хәл ителергә тиеш.

Законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда предприятие бетерелгәндә, предприятие бетерелгәнче күмәк аңлашманамә гамәлдә кала.

15 маддә. Күмәк аңлашманамәне үзгәртү һәм тулыландыру

Гамәли көчендә булган күмәк аңлашманамә күмәк аңлашманамәдә билгеләнгән тәртиптә, әгәр анда каралмаган булса, – аңлашманамә төзү өчен әлеге Законда каралган тәртиптә, бары тик ике якның ризалыгы белән генә үзгәртелә һәм тулыландырыла ала.

16 маддә. Предприятие бетерелгәндә хезмәт коллективына бирелә торган гарантияләр

Предприятие бетерелгәндә хезмәт коллективының күмәк аң-

лашманамә буенча дәгъвалары, бюджет белән банклар һәм башка кредиторлар белән исәп-хисап ясаганчыга кадәр, бетерелүче предприятиенең мөлкәтеннән канәгатьләндерелә. Күмәк аңлашманамә буенча хезмәт коллективының дәгъваларын канәгатьләндерүгә китә торган чараларның күләме, күмәк аңлашманамәгә һәм аңа өстәмәгә имза салган профсоюз органы, ә ул булмаганда, хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле рәвештә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләре белән килешеп, бетерү комиссиясе тарафыннан бүлекчәләргә һәм хезмәткәрләргә билгеләнә һәм үзара бүленә.

17 маддә. Күмәк аңлашманамәнең үтәлешен тикшерү

Күмәк аңлашманамәнең үтәлеше турыдан-туры яклар яки аларның вәкаләтле вәкилләре, югарыдагы хуҗалык һәм профсоюз органнары, шулай ук Татарстан Республикасының хезмәт һәм эш белән тәэмин итү органнары тарафыннан тикшерелә.

Яклар, тикшерү үткәрелгәндә, моның өчен кирәкле булган үзләрендәге барлык мәгълүматларны бирергә тиешләр.

Күмәк аңлашманамәгә имза салган яклар ел саен яисә күмәк аңлашманамәдә каралган вакытларда аның үтәлеше хакында хезмәт коллективының гомуми җыелышында /конференциядә/ хисап тоталар.

## IУ бүлек. Килешүләр

18 маддә. Килешүләрнең төрләре

Көйләүле мөнәсәбәтләр өлкәсенә бәйле рәвештә төп, тармак /тариф/, махсус килешүләр төзелергә мөмкин.

Төп килешү җәмгыяви-икътисади сәясәтне килешеп уздыруның гомуми принципларын билгели.

Тармак /тариф/ килешүе тармакның җәмгыяви-икътисади үсеше юнәлешләрен, хезмәт һәм хезмәткә түләүнең шартларын, тармак хезмәткәрләре /профессиональ төркемнәр/ өчен җәмгыяви гарантияләрне билгели.

Махсус килешү территория үзенчәлекләренә бәйле рәвештә билгеле бер җәмгыяви-икътисади проблемаларны хәл итү шартларын билгели.

Сөйләшүләрдә катнашучы якларның килешүенә карап, килешүләр өч яклы һәм ике яклы булырга мөмкин.

I9 маддә. Килешүләрдә катнашучылар

Килешүләр:

республика дәрәҗәсендә - профсоюзларның республика берләшмәләре, алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле рәвештә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләре белән эш бирүчеләрнең республика берләшмәләре, республика хөкүмәте арасында төзелә;

тармак яисә профессиональ дәрәҗәдә - тиешле профсоюзлар, ә алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле рәвештә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләре белән эш бирүчеләр /эш бирүчеләрнең берләшмәләре/, министрлыклар һәм ведомстволар арасында төзелә;

территориаль дәрәҗәдә - тиешле профсоюзлар /профсоюз берләшмәләре/, ә алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле рәвештә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләре белән эш бирүчеләр /эш бирүчеләрнең берләшмәләре/, башкарма хакимият органнары ара-

сында тәзелә.

20 маддә. Килешүләрне эшләү һәм төзү тәртибе, вакытлары

Килешүләрне эшләү һәм төзү тәртибе, вакытлары әлеге Законның җиденче маддәсендә каралган комиссия тарафыннан билгеләнә һәм әлеге комиссиянең карары нигезендә төзелә.

Тиешле дәрәҗәдә берничә профсоюз /профсоюз берләшмәләре/, алар югында - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләре булганда, хезмәткәрләр ягыннан комиссия әгъзалары әлеге профсоюзлар /профсоюз берләшмәләре/, ә алар булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле рәвештә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләре белән үзара килешеп билгеләнә.

Килешү проекты комиссия тарафыннан эшләнә һәм аңа килешүдә катнашучыларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имза салына.

Яклар тарафыннан имза салынган килешү, аңа өстәмәләр, хәбәр буларак теркәү өчен, жиде көн эчендә килешүдә катнашучы - эш бирүче /эш бирүчеләрнең берләшмәләре/ тарафыннан югарыдагы хуҗалык һәм хезмәт һәм эш белән тәэмин итү буенча республика органнарына җибәрелә.

21 маддә. Килешүләрнең эчтәлеге

Килешүләрнең эчтәлеген яклар билгели.

Килешүләргә түбәндәге положениеләр кертелә:

хезмәткә түләү, хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау, хезмәт һәм ял режимы турында;

бәяләр үсешенә, инфляция дәрәҗәсенә карап, килешүләрдә билгеләнгән күрсәткечләрнең үтәлешеннән чыгып, хезмәткә түләүне көйләү механизмы турында;

минималь күләме законнарда каралган компенсация рәвешендәге өстәмә түләүләр;

хезмәт белән тәэмин итүгә, хезмәткәрләрне яңа һөнәргә өйрәтүгә ярдәм итү турында;

җитештерү урынында экологик куркынычсызлыкны, хезмәткәрләрнең хезмәтен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү турында;

хезмәткәрләрне һәм аларның гаилә әгъзаларын җәмгыяви яклау буенча махсус чаралар турында;

дәүләт һәм муниципаль предприятиеләрне хосусыйлаштырганда хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен кайгырту;

гарипләрне, яшьләрне /шул исәптән яшүсмерләрне/ эш белән тәэмин итү өчен өстәмә хезмәт урыннары булдыручы предприятиеләргә ташламалар турында;

җәмгыяви партнерлыкны һәм өч яклы хезмәттәшлекне үстерүгә, күмәк аңлашманамәләр төзүгә ярдәм итү, хезмәт низагларын һәм эш ташлауларны булдырмый калуга, хезмәт дисциплинасын ныгытуга ярдәм итү турында.

Килешүләрдә законнарга каршы килми торган башка төрле хезмәт һәм җәмгыяви-икътисади мәсьәләләр буенча положениеләр булырга мөмкин.

22 маддә. Килешүнең көче

Килешү яклар имза салган мизгелдән яисә килешүдә билгеләнгән көннән үз көченә керә.

Килешү көченең вакыты һәм аны үтәүне тикшерү тәртибе яклар тарафыннан килешүдә билгеләнә. Килешү үзенең гамәли көчен өч елдан да артык саклый алмый.

Килешү көче килешү эшләүдә һәм килешү төзүдә катнашучыларга вәкаләтләр биреп җибәргән хезмәткәрләргә, эш бирүчеләргә, башкарма хакимият органына кагыла.

23 маддә. Килешүне үзгәртү һәм тулыландыру

Килешү ике якның ризалыгы белән, килешүдә билгеләнгән тәртиптә, әгәр анда билгеләнмәгән булса, килешү төзү өчен әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә үзгәртелә һәм тулыландырыла.

24 маддә. Килешүләрнең үтәлешен тикшерү

Килешүләрнең үтәлешен барлык дәрәҗәдә турыдан-туры яклар яисә аларның вәкаләтле вәкилләре, шулай ук хезмәт һәм эш белән тәэмин итү буенча республика органнары тикшерә.

Яклар, тикшерү үткәрелгәндә, моның өчен кирәкле булган үзләрендәге барлык мәгълүматларны бирергә тиешләр.

У бүлек. Җаваплылык

25 маддә. Сөйләшүләрдә катнашудан читләшкән өчен җаваплылык

Күмәк аңлашманамәне, килешүне төзү, үзгәртү яисә тулыландыру буенча сөйләшүләрдә катнашудан читләшүче яки әлеге Законның алтынчы маддәсендәге икенче өлешендә билгеләнгән вакытны бозучы яисә яклар билгеләгән вакытта тиешле комиссияне эш белән тәэмин итмәүче эш бирүче, эш бирүчене белдергән затлар, дәүләт идарәсе органнарының урындагы затлары, профсоюз органы җитәкчеләре яисә хезмәт ияләренең үз вәкилләре хөкем итү тәртибендә салына торган биш минималь хезмәт хакына кадәр күләмдәге штрафка җәлеп ителәләр.

26 маддә. Күмәк аңлашманамәләрне һәм килешүләрне төзү, яңадан карау һәм үтәү буенча эшчәнлеккә комачаулаган өчен җаваплылык

Хезмәткәрләрнең һәм аларның вәкилләренең законлы хокукларын

чикли торган яисә аларны гамәлгә ашыруда комачаулый торган тыкшынулар өчен эш бирүче, эш бирүчене белдергән затлар, дәүләт идарәсе органнарының урындагы затлары хөкем иту тәртибендә салына торган биш минималь хезмәт хакына кадәр күләмдәге штрафка җәлеп ителәләр.

27 маддә. Күмәк аңлашманамәне, килешүне бозган һәм үтәмәгән өчен җаваплылык

Күмәк аңлашманамә, килешү буенча йөкләмәләрне бозуда һәм үтәмәүдә гаепле затлар хөкем иту тәртибендә салына торган биш минималь хезмәт хакына кадәр күләмдәге штрафка җәлеп ителәләр.

Профсоюз, ә ул булмаганда - хезмәт ияләренең Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле рәвештә сайланган һәм вәкаләтләр бирелгән үз вәкилләре таләбе буенча милекче, хуҗалык идарәсе органы күмәк аңлашманамәдәге йөкләмәләрне бозган һәм үтәмәгән житәкчегә карата законда каралган чараларны күрергә тиеш.

28 маддә. Күмәк сөйләшүләр алып бару һәм тикшерү уздыру өчен кирәкле мәгълүматларны бирмәгән өчен җаваплылык

Күмәк сөйләшүләр алып бару һәм күмәк аңлашманамәләрнең, килешүләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны бирмәүдә гаепле эш бирүче, эш бирүчене белдергән затлар,дәүләт идарәсе органнарының урындагы затлары дисциплинар җаваплылыкка яисә хөкем иту тәртибендә салына торган өч минималь хезмәт хакына кадәр күләмдәге штрафка җәлеп ителәләр.

213



29 маддә. Җаваплылыкка җәлеп итү

Әлеге Законда каралган штрафлар салу турындагы эшләрне карау тәртибе һәм вакытлары административ хокук бозулар турында гамәлдәге законнар тарафыннан билгеләнә.

Әлеге маддәнең беренче өлешендә күрсәтелгән эшләр күмәк аңлашманамәнең, килешүнең яклары, тиешле комиссияләрнең тәкъдиме яки прокурорның үз белдеге белән карала.

Түләтелгән штраф суммасы Законда билгеләнгән тәртиптә гаепле аерым затлар исәбеннән кайтарыла.

Штраф салу гаепле затларны әлеге Законда каралган йөкләмәләрне үтәмәүдән азат итми.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1992 елның 25 декабре
№ 1710-XII